СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**26 март, 2024 ел** **№ 390**

# Эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайлау йогынтысын бәяләү һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы карарлар әзерләү һәм кабул итү өлешендә муниципаль идарә процессларының нәтиҗәлелеген һәм камилләштерелүен арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайлау йогынтысын бәяләү һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеген эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль норматив хокукый актларның җайга салу йогынтысын бәяләү һәм эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау өлкәсендә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълуматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Биектау

муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының Бюджет, финанс һәм икътисадый сәясәт комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль
районы Советының 2024 елның
26 март 390нчы номерлы
карары белән расланды

**Эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайлау йогынтысын бәяләү һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү тәртибе турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә, мөнәсәбәтләрне җайга салуның максатка ярашлылыгы һәм альтернатива нәтиҗәлелеге критерийларының сыйфатын һәм аларга туры килүен арттыру, эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына ярдәм күрсәтү кагыйдәләрен һәм тәртибен билгеләү максатларында, муниципаль норматив хокукый актлар проектларының (алга таба - актлар проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза уздыру тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.

1.3. Муниципаль норматив хокукый акт проекты эшчәнлекләре өлкәсенә эшләнә торган акт проекты (алга таба - профильле бүлекчәләр) керә торган Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре, муниципаль учреждениеләре тарафыннан әзерләнә.

1.4. Җайга салу йогынтысын бәяләү өлкәсендә вәкаләтле орган актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрүне һәм норматив хокукый актларга экспертиза ясауны норматив һәм методик тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

1.5. Эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы актлар проектларының җайга салу йогынтысын һәм норматив хокукый актларга экспертиза ясауны бәяләү «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 131-ФЗ номерлы

Федераль закон), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 27 августындагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан кабул ителә (чыгарыла) торган Татарстан Республикасында гамәлдәге норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын гавами бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1182 номерлы карары, әлеге нигезләмә һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә уздырыла.

1.6. Вәкиллекле органнарның җирле салымнарны һәм җыемнарны билгели, үзгәртә, туктатып тора, юкка чыгара торган норматив хокукый актлары проектларыннан, вәкиллекле органнарның бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар проектларыннан һәм гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорга табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлары проектларыннан тыш, эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен яңа бурычларны билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысы бәяләнергә тиеш.

1.7. Дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләрне, конфиденциаль характердагы белешмәләрне үз эченә алган яисә мондый норматив хокукый актларны бары тик федераль һәм региональ законнарга туры китерү максатларында муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертүгә юнәлдерелгән муниципаль актлар проектларының, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне, кризислы хәлләрне булдырмау һәм террорчылык актларын кисәтү, һәм (яисә) аларның нәтиҗәләрен бетерү максатларында эшләнгән муниципаль актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү гамәлгә ашырылмый.

1.8. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм норматив хокукый актларга экспертиза ясауны бастырып чыгару өчен рәсми сайт булып, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге сайты (алга таба - рәсми сайт) тора.

## 2. Җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү

2.1. Акт проектын эшләү турында карар кабул ителгән очракта, профильле бүлекчәләр түбәндәге гамәлләрне башкаралар:

- аларны чишү өчен норматив хокукый акт кабул итү таләп итеЛә торган проблемаларны билгелиләр;

- хокукый җайга салуны кертүнең максатын билгелиләр;

- ачыкланган проблемаларны хәл итүнең мөмкин булган барлык вариантларын ачыклыйлар һәм тасвирлыйлар, моңа яңа хокукый җайга салу кертмичә куелган максатларга ирешергә мөмкинлек бирәчәк вариантларны да кертеп;

- чыгымнарны һәм табышны да кертеп, проблемаларны хәл итүнең тәкъдим ителгән вариантлары китерәчәк нәтиҗәләрен ачыклыйлар һәм бәялиләр, шулай ук тәкъдим ителгән һәр вариантны практикада гамәлгә ашырганда эффективлыгын һәм нәтиҗәлелеген бәялиләр.

2.2. Акт проектына түбәндәге белешмәләрне үз эченә алырга тиешле җыелма хисап кушымта итеп бирелә:

1) муниципаль җайга салу аның чишелешенә юнәлдерелгән проблеманы, аның сәбәпләрен, проблеманың вакыт эчендә үсеше динамикасын һәм фаразын тасвирлау;

2) хәзерге вакытта муниципаль җайга салу гамәлгә ашырыла торган норматив хокукый актлар яисә аларның аерым нигезләмәләре;

3) проблемаларны бетерү (тискәре йогынтыны минимальләштерү) вариантлары, шул исәптән хокук куллану практикасын камилләштерү, шулай ук норматив хокукый актларны эшләү, үзгәртү яисә бетерү юлы белән;

4) муниципаль җайга салу максатлары;

5) муниципаль җайга салу юнәлдерелгән эшкуарлык, башка икътисадый эшчәнлек субъектлары төркеменә характеристика;

6) җирле үзидарә органнарының яңа функцияләре, вәкаләтләре, бурычлары һәм хокуклары яисә аларны үзгәртү турында белешмәләр, шулай ук аларны гамәлгә ашыру тәртибе;

7) билгеләнгән вазыйфаларны яисә чикләүләрне үтәү зарурлыгына яисә мондый вазыйфаларның яисә чикләүләрнең эчтәлеге үзгәрүгә бәйле муниципаль бюджет, эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары чыгымнарын (мөмкин булган кертемнәрен) бәяләү;

8) ачыкланган проблеманың торышын чагылдыра торган муниципаль җайга салу максатларына ирешүне мониторинглауның индикаторлары (күрсәткечләре), әлеге индикаторларның җайга салу өлкәсендәге проблемаларны анализлау вакытына кыйммәте һәм индикаторлар кыйммәтләре турында мәгълүмат чыганагы;

9) акт проектының файдасын һәм чыгымнарын тасвирлау: йогынты тәэсир иткән социаль төркемнәр, икътисадый секторлар, территорияләр; көтелгән тискәре һәм уңай йогынты;

10) норматив хокукый акт кабул итүгә бәйле куркынычларны һәм чыгымнарны бәяләү;

11) норматив хокукый акт кабул итүгә бәйле көтелгән нәтиҗәләр, чикләүләр;

12) акт проекты үз көченә керүнең фаразлана торган датасын;

13) җайга салу максатына ирешүнең сайланган ысулының нәтиҗәлелеген тикшереп тору ысулларын тасвирлау;

14) җайга салуның күрсәтелгән максатларына ирешү өчен кирәкле оештыру-техник, методологик, мәгълүмати һәм башка чаралар;

15) хәбәрнамәне урнаштыру, мондый урнаштыруга бәйле рәвештә тәкъдимнәр бирү сроклары турында белешмәләр;

16) профильле бүлекчә фикеренчә, тәкъдим ителә торган җайга салуның нигезлелеген бәяләргә мөмкинлек бирә торган башка белешмәләр.

2.3. Эшкуарлык һәм башка эшчәнлек субъектларының фикерен исәпкә алу максатларында акт проектын бәяләүне уздыру кысаларында Профильле бүлекчә тарафыннан гавами консультацияләр уздырыла.

2.4. Гавами консультацияләр уздыру өчен профильле бүлекчә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында гавами консультацияләр уздыру турында хәбәр урнаштыра, аңа карата бәяләү үткәрелә торган акт проекты, шулай ук җыелма хисап, гавами консультацияләр барышында тикшерелә торган акт проекты буенча сораулар исемлеге аңа кушымта итеп бирелә. Хәбәрнамәдә гавами консультацияләр уздыру срогы, шулай ук гавами консультацияләрдә катнашучылар тарафыннан гавами консультацияләр барышында тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен җибәрү ысулы күрсәтелә.

2.5. Гавами консультацияләр нәтиҗәләре белешмә рәвешендә ачык консультацияләр тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә Профильле бүлекчә тарафыннан рәсмиләштерелә.

2.6. Гавами консультацияләр уздыру срогы 10нан ким 30дан артык булмаган календарь көн тәшкил итә.

2.7. Актның эшләп бетерелгән проекты, аңлатма язуы, акт проектының конкуренция торышына йогынтысын анализлау һәм гавами консультацияләр нәтиҗәләре буенча белешмә гавами консультацияләр тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә бәяләү турында бәяләмә әзерләү өчен Вәкаләтле органга җибәрелә.

2.8. Вәкаләтле орган 10 эш көне дәвамында кушып бирелгән документлар белән акт проектын карый, аны бәяләү нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли һәм аны өч эш көне эчендә профильле бүлекчәгә җибәрә.

2.9. Акт проектын бәяләүне үткәргәндә Вәкаләтле орган профильле бүлекчәдән акт проектын бәяләүне уздыру өчен кирәкле бөтен мәгълүматны соратып ала.

2.10. Акт проектын бәяләү нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле орган тарафыннан төзелә торган бәяләмәдә әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләрнең акт проектында булуы яисә булмавы турында нәтиҗә ясала.

2.11. Бәяләү турында бәяләмә нәтиҗәләре буенча профильле бүлекчә Вәкаләтле орган кисәтүләрен бетерергә тиеш.

2.12. Әгәр Вәкаләтле органның бәяләмәдә китерелгән нәтиҗәләрен профильле бүлекчә нигезсез дип санаса, профильле бүлекчә тарафыннан Вәкаләтле орган белән килештерелгән позициягә ирешү максатларында килештерү процедуралары үткәрелә. Килештерелгән позициягә ирешмәгән очракта, профильле бүлекчә тарафыннан беркетмә рәсмиләштерелә, ул профильле бүлекчә җитәкчесе (яисә аның урынбасары) һәм Вәкаләтле орган җитәкчесе (яисә аның урынбасары) тарафыннан имзалана.

Проект буенча материалларга акт проектын кабул итү процедурасын алга таба гамәлгә ашырганда, килештерү процедуралары нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән беркетмә мәҗбүри тәртиптә кушымта итеп бирелә.

Акт проектын әзерләүдән баш тарту яисә аны эшләп бетерү турында карар кабул ителгән очракта, профильле бүлекчә җайга салу йогынтысын бәяләү турында бәяләмә һәм акт проекты буенча тәкъдимнәр җыелмасын алган көннән алып 15 календарь көннән дә соңга калмыйча, тиешле мәгълүматны рәсми сайтка урнаштыра.

Әлеге нигезләмәнең 1.2 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләрнең акт проектында ачыклануы булмаган очракта, профильле бүлекчә акт проектының йомгаклау редакциясен, шулай ук җайга салу йогынтысын бәяләү турында бәяләмә һәм акт проекты буенча тәкъдимнәр җыелмасын алган көннән соң 15 календарь көннән дә соңрак булмаган срокта акт проекты буенча гавами консультацияләрдә катнашучылардан кергән үзе алган тәкъдимнәр җыелмасында булган тәкъдимнәрне исәпкә алу яисә кире кагу сәбәпләре турындагы мәгълүматны әзерли.

## 3. Норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү

3.1. Норматив хокукый актлар экспертизасы (алга таба - экспертиза) Вәкаләтле орган тарафыннан норматив хокукый актларга экспертиза уздыруның еллык планнары нигезендә үткәрелә.

3.2. Норматив хокукый актка экспертиза уздыру өчен нигез булып эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек өлкәсендә иҗтимагый

оешмалардан, кулланучылар берләшмәләреннән, җирле үзидарә органнарыннан, үз-үзен җайга сала торган оешмалардан тәкъдимнәр, Вәкаләтле орган тарафыннан эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә проблемалар булуны мөстәкыйль ачыклау тора, шул исәптән түбәндәгеләр нәтиҗәсендә:

1) муниципаль норматив хокукый актларны мониторинглау;

2) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый торышын мониторинглау;

3) гражданнар һәм оешмалардан җирле үзидарә органнарына билгеле бер эшкуарлык, инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә проблемалар барлыгын раслый торган күпсанлы мөрәҗәгатьләр керүе.

3.3. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне яисә конфиденциаль характердагы белешмәләрне үз эченә алган, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне, кризис хәлләрен һәм террорчылык актларын кисәтүне булдырмау һәм (яисә) аларның нәтиҗәләрен бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актларга экспертиза үткәрелми.

3.4. Норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү этаплары түбәндәгеләр:

1) норматив хокукый актларга экспертиза уздыру планын формалаштыру;

2) муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмәләр проектларын әзерләү;

3) норматив хокукый актларга экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмәләр проектлары буенча гавами консультацияләр уздыру;

4) норматив хокукый актларга экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмәләр әзерләү.

3.5. Норматив хокукый актларга экспертиза уздыру планында түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) муниципаль норматив хокукый акт исеме һәм реквизитлары;

2) норматив хокукый актны эшләүне гамәлгә ашыручы бүлекчә исеме;

3) норматив хокукый актка экспертиза уздыру, шул исәптән гавами консультацияләр срогы.

3.6. Вәкаләтле орган агымдагы ел тәмамланганга кадәр дүрт айдан да соңга калмыйча муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында план төзү максатларында тәкъдимнәр җыю турында хәбәр урнаштыра.

3.7. Тәкъдимнәрне җыю чоры, хәбәрнамә урнаштырылган вакыттан алып, 30дан ким һәм 45тән артык булмаган календарь көн тәшкил итә.

3.8. Вәкаләтле орган тәкъдимнәрне җыю срогы тәмамланган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча план төзи һәм раслый. План муниципаль

берәмлекнең рәсми сайтында аны раслаган көннән алып ике эш көне эчендә урнаштырылырга тиеш.

3.9. Норматив хокукый актларга экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмә түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

1) муниципаль норматив хокукый актның төп реквизитларын;

2) норматив хокукый акт кабул иткән һәм (яисә) компетенциясенә һәм вәкаләтләренә тикшерелә торган иҗтимагый мөнәсәбәтләр даирәсе керә торган орган исемен;

3) муниципаль акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны (ул үткәрелгән очракта);

4) карала торган муниципаль норматив хокукый актның һәм аның аерым нигезләмәләренең гамәлдә булу срогын;

5) муниципаль норматив хокукый актта билгеләнгән җайга салуга кызыксынулары кагыла торган затлар даирәсен (алга таба - җайга салу);

6) проблеманы хәл итү һәм аңа бәйле җайга салу исәбенә тискәре эффектларны җиңүләр дәрәҗәсен бәяләүне;

7) әлеге муниципаль норматив хокукый актны гамәлгә ашырудан чыгымнарны һәм керемнәрне бәяләүне;

8) җайга салуның факттагы уңай һәм тискәре нәтиҗәләрен бәяләүне;

9) игълан ителгән җайга салу максатларына һәм күрсәткечләренә ирешүнең нәтиҗәлелеген бәяләүне;

10) муниципаль норматив хокукый актта эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек алып баруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләр барлыгы турында белешмәләрен;

11) эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрне бетерү ысуллары һәм гамәлдәге җайга салуның нәтиҗәлелеген арттыру турындагы тәкъдимнәрне;

12) җайга салуның фактагы йогынтысын бәяләргә мөмкинлек бирә торган башка белешмәләрен.

3.10. Муниципаль норматив хокукый актка экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмә проекты Профильле бүлекчә тарафыннан әзерләп куела һәм вәкаләтле органга җибәрелә.

3.11. Муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмә проекты Вәкаләтле орган тарафыннан гавами консультацияләргә чыгарыла. Муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмәләр проектлары буенча гавами консультацияләр уздыру өчен, Вәкаләтле орган муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында аларны үткәрү турында хәбәрнамә, экспертиза үткәрелә торган

норматив хокукый акт, муниципаль норматив хокукый актка экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмә проектын урнаштыра.

3.12. Хәбәрнамә гавами консультацияләр уздыру срогын һәм гавами консультацияләрдә катнашучыларның үз фикерләрен җибәрү ысулын үз эченә алырга тиеш.

3.13. Муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмәләр проектлары буенча гавами консультацияләр уздыру срогы 10нан ким һәм 30дан артык булмаган календарь көн тәшкил итә.

3.14. Биш эш көне эчендә гавами консультацияләр уздыру нәтиҗәләре буенча белешмә әзерләнә, ул муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү өчен нигез булып тора.

3.15. Норматив хокукый актка экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмә имзаланган көннән соң ике эш көне дәвамында Вәкаләтле орган тарафыннан профильле бүлекчәгә җибәрелә. Экспертиза йомгаклары буенча Вәкаләтле орган җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр җибәрә.

3.16. Муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза нәтиҗәләре турындагы бәяләмә аларга үзгәрешләр кертү яисә аларны гамәлдән чыгару өчен нигез булып тора.